# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Күгәрчен авыл җирлеге Күгәрчен торак пунктында

2022 елның 30 ноябре № 2

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, № 45-ТРЗ «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы закон нигезендә Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының Күгәрчен авыл җирлегендә гражданнар җыены

Карар:

1. 2023 елда Балык Бистәсе муниципаль районының Күгәрчен авыл җирлеге территориясендә Күгәрчен т.п яшәү урыны буенча теркәлгән сайлау хокукына ия булган һәр кешедән , көндезге формада белем алучы студентлардан, балачактан инвалидлардан, беренче группа инвалидлардан, 80 яшькә җиткән ялгыз яшәүче пенсионерлардан, мобилизаөиялнгән грагражданнардан һәм аларның гаилә әгъзаларыннан тыш, (гомуми саны 30 проценттан артмаган очракта) 500 сум күләмендә гражданнарның үзара салымын кертергә.
2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрергә:

- торак пункт чикләрендә җирле әһәмияттәге гомуми файдаланудагы автомобиль юлларын төзү, ремонтлау;
- су белән тәэмин итү системаларын, су башняларын, скважиналарны һәм башка су белән тәэмин итү инженерлык корылмаларын ремонтлау;
- Күгәрчен авылы һәм Зангар-Күл авылы торак пунктларында юлларны кышкы карап тоту;
- Күгәрчен, Зангар-Күл авыллары урамнарын ремонтлау өчен вак таш сатып алу;
- Күгәрчен, Зангар-Күл авыллары урамнарын ремонтлау өчен вак таш ташу буенча транспорт хезмәтләре өчен түләү.

.Җыен нәтиҗәләрен Татарстан Республикасы, Балык Бистәсе муниципаль районы, Күгәрчен авылы, Зәет урамы, 1А йорты, инфармация стендларында; Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендәге рәсми сайтында һәм

http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча “Интернет” мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендәге “Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталы” ында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче: А. Т. Сафин

Күгәрчен авыл җирлеге
башлыгы: А. Т. Сафин